Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге Советы

Шәле авыл җирлеге башлыгы
# КАРАРЫ

5 август, 2026 ел № 9

Шәле авылы

## Җир кишәрлегеннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге Советының 2017 елның 21 августындагы 15 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә (2017 елның 13 декабрендәге 30 номерлы, 2018 елның 25 маендагы 12 номерлы, 2019 елның 7 октябрендәге 52 номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 57 номерлы, 2023 елның 31 мартындагы 64 номерлы, 2024 елның 15 мартындагы 2 номерлы карары белән) карар бирәм:

1.Түбәндәге проект буенча гавами тыңлаулар үткәрүне билгеләргә:

1.1 - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы (Татарстан), Питрәч муниципаль районы, Шәле авыл җирлеге, Люткино авылы, Долгая ур., 1 ж/к адресы буенча урнашкан 16:33:170301:24 кадастр номерлы, 2702 кв.м мәйданлы җир кишәрлегеннән - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Шәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең индивидуаль торак төзелеше зонасында (Ж1) «дини файдалану» файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турында Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы боерыгы проекты.

2. Гавами тыңлауларны үткәрүне оештыручыны - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шәле авыл җирлеге башкарма комитеты билгеләргә (алга таба - Башкарма комитет).

3. Гавами тыңлауларны оештыручыга - Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Шәле авыл җирлеге башкарма комитетына җирле үзидарә турындагы, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы кануннар нигезендә гавами тыңлауларны оештыруны һәм уздыруны тәэмин итәргә.

4. Гавами тыңлаулар үткәрү 2026 елның 4 сентябреннән дә соңга калмыйча тәгәлләнергә тиеш дип билгеләргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Питрәч муниципаль районы
Шәле авыл җирлеге башлыгы И.Р. Әхмәтҗанов